**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИЕКТАУ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422701 Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Биектау авылы, Зур Кызыл урамы, 113А йорт

**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422701, Республика Татарстан, Высокогорский
район,с. Высокая Гора, ул. Б. Красная, д. 113А

Тел./факс: +7(84365) 74-7-79 e-mail: Vgor.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**
**04.03.2026 ел** **№ 8**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Биектау авыл җирлегендә торак пунктлардагы территориянең бер өлешендә гражданнар җыенын билгеләү турында Пермяки авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 нче статьясына, Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Уставының 24 нче статьясы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Биектау авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә (кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге Советы

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. 2026 елның 16 мартында 17 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Пермяки авылы торак пункты территориясендә — Клубная, Озерная ур. адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә: Пермяки авылы, Клубная урамы, 57 нче номерлы йорт янында.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Пермяки авылы торак пунктының Верхняя ур. территориясе өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2026 елда 10000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп, түбәндәге эшләр башкару белән килешәсезме:
- тротуарларны төзү, ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат телекоммуникация

челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә): http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә

Совет рәисе,
Биектау авыл җирлеге башлыгы Р.Ф. Салихзянов